ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 17.08.2023
1199
КАРАР

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар хакында» 2016 елның 21 гыйнварындагы 91 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 21 июлендәге 67-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар хакында» 2016 елның 21 гыйнварындагы 91 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Вәкаләтле вазыйфаи затларга Татарстан Республикасы Кодексының 2.1 (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы, предприятие, учреждение, башка оешмаларның исемнәрен һәм башка белешмәләрне элмә тактада күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуга карата), 2.4-2.8, 2.12-2.14, 2.15 статьяның 2 өлеше , 2.16, 2.17, 3.2-3.8, 3.10 (гражданнарга карата), 3.11, 3.14-3.17, 4.4, 5.1, 5.2, 5.6 (тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль ташуга карата) статьяларында каралган,

административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү хокукын, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге вазифаи затларына йөкләргә:

- муниципаль контроль бүлеге башлыгына;
- муниципаль контроль бүлегенең баш белгеченә;
- тәртип саклау буенча җәмәгать пунктларының баш белгеченә;
- тәртип саклау буенча җәмәгать пунктларының әйдәп баручы белгеченә.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.Л. Исланов